«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры

_____________ Э.Н. Фәттахов

"_7_" _ноябрь_ 2016 нчы ел

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2017 нче елда татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты

## (җиңеләйтелгән вариант)

**Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның рус төркемнәрендә IX сыйныф укучыларына (җиңеләйтелгән враиант) татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар**

2017 нче елгы бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән биремнәр 2017 нче елда тест үткәрү материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмый. 2016 нчы елгы бердәм республика тестында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге рус телендә урта гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен бердәм республика тестына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә бердәм республика тесты материалларының структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Күрсәтмә вариант материаллары чыгарылыш сыйныф укучыларында бердәм республика тестына әзерлек осталыгын булдырачак.

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты (җиңеләйтелгән вариант)**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Татар теленнән бердәм республика тестын үтәү өчен 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә.

Татар теленнән тест эше 38 биремне үз эченә алган 4 бүлектән тора. **1 нче бүлектә** 8 бирем (1 – 8 нче биремнәр) бар. Алар укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлек** 9 биремнән тора (9 – 17 нче биремнәр). Алар укучыларның укып аңлау күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлек** 15 биремнән тора (18 – 32 нче биремнәр). Алар укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлек** 2 өлештән тора. 33 – 37 нче биремнәр сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тота. Ачык типтагы 38 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

Тест биремнәрен үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә. Караламадагы язулар тикшерелми!

**Уңышлар телибез!**

*****

**Единое республиканское тестирование по ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ для обучающихся, освоивших программу основного общего образования в русских группах учреждений с русским языком обучения (облегченный вариант)**

**Инструкция по выполнению работы**

Время, отведенное на выполнение всей тестовой работы – 2 часа 30 минут (150 минут).

Тестовая работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 38 заданий. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 8 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1-8). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 9 заданий (задания 9-17). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 15 заданий (задания 18-32). **Раздел 4** (задания по письму) состоит из двух частей. В заданиях 33-37 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией. В задании 38 предлагается написать личное письмо.

Во время выполнения теста разрешается пользоваться орфографическим словарем. Записи в заданиях и черновиках не проверяются!

**Желаем успеха!**

## 1 нче бүлек

***Ответом к заданиям 1 и 2 является последовательность цифр, запишите её в бланке ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. При переносе ответа на бланк следует указать только эту последовательность, без запятых, пробелов и прочих символов. Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.***

**1** ***Вы услышите четыре коротких диалога, обозначенных А, Ә, Б и В. Определите, где происходит каждый из этих диалогов. Используйте каждое место действия из списка 1-5 только один раз. В задании есть одно лишнее место действия. Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.***

1. Өс киемнәре кибетендә
2. Аяк киеме кибетендә
3. Китап кибетендә
4. Ашамлыклар кибетендә
5. Җиһазлар кибетендә

Ответ:

| **Диалог** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** |
|---|---|---|---|---|
| **Место действия** | | | | |

**2** Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего **А – Г** и утверждениями, данными в списке **1 - 6.** Используйте каждое утверждение из списка 1-6 **только один раз.** В задании есть **одно лишнее утверждение.**
Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.

1. Сөйләүче кунакханә турында әйтә.
2. Сөйләүче театр турында әйтә.
3. Сөйләүче ашханә турында әйтә.
4. Сөйләүче китапханә турында әйтә.
5. Сөйләүче зоопарк турында әйтә.
6. Сөйләүче цирк турында әйтә.

Ответ:

| **Говорящий** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Утверждение** | | | | | |

***Вы услышите разговор двух друзей. В заданиях 3 – 8 обведите цифру 1, 2 или 3, соответствующую выбранному Вами варианту ответа.***
***Вы услышите запись дважды.***

**3** Алсу … лагерьда ял иткән.

1) язын
2) җәен
3) кышын

**4** Лагерь … урнашкан.

1) чит илдә
2) шәһәрдә
3) урманда

**5** Самат … булган.

1) спорт лагеренда
2) күлдә
3) бакчада

**6** Самат җәен ….

1) велосипедта йөргән
2) су коенган
3) укыган

**7** Алсу … белән кызыксына.

1) спорт
2) чит телләр
3) җыр

**8** Самат белән Алсу - … .

1) спортчылар
2) укытучылар
3) укучылар

***По окончании выполнения заданий 1- 8 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1.***

## 2 нче бүлек

***Прочитайте текст. Определите, какие из приведённых утверждений 9 - 16 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми).***

Безнең мәктәп яңа. Ул дүрт катлы, зур һәм бик матур.

Беренче катта ашханә, китапханә, актлар залы, спорт залы урнашкан. Икенче, өченче, дүртенче катларда сыйныф бүлмәләре. Алар якты һәм уңайлы. Коридорлар иркен, тәрәзәләр биек. Коридорларда гөлләр үсә, ял итү өчен урыннар бар.

Мәктәптә бер меңнән артык укучы укый. Укулар бер сменада бара. Мәктәптә төрле кабинетлар эшли: рус теле һәм әдәбияты кабинеты, татар теле һәм әдәбияты кабинеты, математика, биология, физика, химия, география кабинетлары. Алар барысы да укучыларга бик ошый.

Мәктәпнең спорт залы да зур. Анда физкультура дәресләре үтә. Залда укучылар волейбол, баскетбол уйныйлар. Безнең мәктәп укучылары төрле спорт ярышларында катнашалар. Безнең сыйныф укучылары арасында мәктәп чемпионы да бар: иң яхшы теннисчы.

Мәктәптә төрле түгәрәкләр эшли: шахмат түгәрәге; математика түгәрәге; хор түгәрәгере, гимнастика түгәрәге һәм башкалар.

**9** Мәктәп биш катлы.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**10** Китанханә мәктәпнең беренче катында.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**11** Сыйныф бүлмәләре башка катларда урнашкан.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**12** Мәктәп тәрәзәләре кечкенә.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**13** Мәктәптә меңгә якын бала укый.

1) текстка туры килә  2) текстка туры килми

**14** Мәктәптә кабинетлар бик күп.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**15** Физкультура дәресләре зур спорт залында була.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**16** Мәктәптә өч түгәрәк эшли.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**17** ***Прочитайте тексты и установите соответствие между текстами А – Е и заголовками 1 - 8. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую цифру только один раз. В задании есть один лишний заголовок. Получившуюся последовательность цифр запишите в бланк ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. При переносе ответа на бланк следует указать только эту последовательность, без запятых, пробелов и прочих символов. Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.***

1. **Бәйрәмнең башлануы**
2. **Конкурста җиңү**
3. **Балаларның кайтуы**
4. **Әниләрнең рәхмәте**
5. **Укучыларның әзерләнүе**
6. **Бәйрәмне көтеп алу**
7. **Балаларның чыгышлары**
8. **Беренче кунаклар**

**А.** Бүген мәктәптә Әниләр көнен бәйрәм итәләр. Укучылар актлар залын бизәделәр, өстәлләргә чәчәкләр куйдылар.

**Ә.** Менә әниләр килә башлады. Беренче булып, Ларисаның әнисе килде. Ул банкта программист булып эшли. Ларисаның да әнисе кебек программист буласы килә. Аннары Гүзәлнең әнисе килде. Ул инженер, заводта эшли.

**Б.** Ниһаять, әниләр барысы да җыелып беттеләр. Бәйрәм башланды. Башта мәктәп директоры әниләрне бәйрәм белән котлады, аларга матур теләкләр теләде. Соңыннан балалар әниләргә чәчәкләр бирделәр.

**В.** Концерт та матур булды. Лилия белән Настя татарча җыр җырладылар, ә Булат үзенең шигырьләрен укыды.

**Г.** Аннан соң укучылар төрле конкурслар оештырдылар. Соңгы конкурста Илдарның әнисе җиңеп чыкты, чөнки иң тәмле салат аныкы иде.

**Д.** Бәйрәм кичәсе бик күңелле үтте. Әниләр балаларга, укытучыларга зур рәхмәтләр әйтеп киттеләр.

**Е.** Мәктәптә әниләр бәйрәмен үткәрү матур бер традициягә әйләнде. Ел саен әниләр дә, без дә бу бәйрәмне көтеп алабыз.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** | **Е** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | | | |

***По окончании выполнения заданий 9-17 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1.***

**3 нче бүлек**

***Ответы на задания 18 - 25 запишите в бланке ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.***

***Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 18 – 25 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответсвует отдельному заданию 18-25.***

| | | |
|---|---|---|
| **18** | Дүрт ел … бар: кыш, яз, көз, җәй. | ФАСЫЛ |
| **19** | Кышын балалар чанада, чаңгыда, ... шуарга яраталар. | ТИМЕРАЯК |
| **20** | Алар кар бабай ясыйлар, хоккей .. . | УЙНАРГА |
| **21** | … соң яз килә. | КЫШ |
| **22** | Язын табигать матурлана, … беренче чәчәкләр күренә. | УРМАН |
| **23** | ... соң җәй килә. | ЯЗ |
| **24** | Җәй – ял ... . | ВАКЫТ |

| 25 | Җәйдән соң көз килә, һәм ... яңгырлы була. | КӨН |
|---|---|---|

***Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 26 – 32 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию 26 – 32.***

| | | |
|---|---|---|
| 26 | Мәктәптә без ... телләр өйрәнәбез: рус, татар, инглиз телләре. | ТӨР |
| 27 | Телләр белү – зур ... ул. | БАЙ |
| 28 | Татар теле дәресләрендә без ... сөйләшәбез, текстлар укыйбыз, язабыз. | ТАТАР |
| 29 | Татар теле дәресләрендә без Татарстан, Казанның ... урыннары турында сөйләшәбез. | ИСТӘЛЕК |
| 30 | Татар теле дәресләрен мин яратам, чөнки укытучыбыз бер-беребезне тыңларга, ... өйрәтә. | АҢ |
| 31 | Минемчә, татар телен белү бик ..., чөнки ул Татарстанда дәүләт теле. | ӘҺӘМИЯТ |
| 32 | Хәзерге вакытта күп телләр белү ... . | ФАЙДА |

***По окончании выполнения заданий 18 –32 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1.***

## 4 нче бүлек

***Для ответа на задания 33- 38 используйте бланк ответов № 2.***
***При выполнении заданий 33 - 38 обратите внимание на то, что ваши ответы будут оцениваться только по записям, сделанным на бланке № 2. Записи в черновиках при проверке экспертом не учитываются.***

***В заданиях 33 - 37 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуацияләренә туры килгән репликаларны языгыз.**

33 Скажите, что вы учитесь в девятом классе.

34 Попросите у одноклассника карандаш.

35 Поинтересуйтесь у учителя, будете ли вы смотреть на уроке татарские мультфильмы.

36 Подтвердите, что сегодня холодно.

37 Поздравьте учителя татарского языка с Днем знаний.

38 **Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Аның сорауларына җавап биреп, хат языгыз. Язма эшегез 40 сүздән торырга тиеш.**

*... Кичә минем туган көнем булды. Дусларым миңа кунакка килделәр. Алар белән бик күңелле булды.*

*.. Ә синең туган көнең кайчан? Туган көнеңә кемнәр килә? Алар белән ничек бәйрәм итәсез?*

**Татар теленнән бердәм республика тестын бәяләү системасы**
**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

| |
|---|
| Сейчас Вы будете выполнять задания по аудированию. Каждый текст прозвучит 2 раза. После первого и второго прослушивания у Вас будет время для выполнения и проверки заданий. Все паузы включены в аудиозапись. Остановка и повторное воспроизведение аудиозаписи не предусмотрены. |

**Задание 1**

| |
|---|
| Вы услышите четыре коротких диалога, обозначенных **А, Ә, Б и В.** Определите, где происходит каждый из этих диалогов. Используйте каждое место действия из списка **1-5 только один раз.** В задании есть **одно лишнее место действия.** Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу. У Вас есть 20 секунд, чтобы ознакомиться с заданием. |

**Диалог А.**
А: Исәнмесез! Миңа 1 литр сөт, эремчек һәм күмәч бирегезче.
Ә: Исәнмесез! Яхшы.
А: Миңа каймак та кирәк әле. Сездә бармы?
Ә: Әйе, хәзер алып киләм.
А: Рәхмәт!

**Диалог Ә.**
А: Хәерле көн!
Ә: Хәерле көн!
А: Миңа Лев Толстойның “Сугыш һәм солых” китабы кирәк. Сездә бармы?
Ә: Әйе, әлбәттә. Китап рус телендә кирәкме яки татарчамы?
А: Татарча. Ничә сум тора?
Ә: Бер томы - 280 сум.
А: Яхшы, мин алам.

**Диалог Б.**
А: Исәнмесез!
Ә: Исәнмесез!
А: Миңа бу зәңгәр кроссовкаларны күрсәтегезче.
Ә: Яхшы. Сезгә ничәнче үлчәм кирәк?
А: 38 нче үлчәм. Алар ничә сум тора?
Ә: Хәзер карыйм. Өч мең алты йөз сум.
А: О-О кыйбат!
Ә: Әйе, ләкин бик сыйфатлы.

**Диалог В.**
А: Исәнмесез! Сездә 44 нче үлчәмле ак футболкалар бармы?
Ә: Исәнмесез! Әйе, бар.

А: Миңа күрсәтегезче. Алар рәсемлеме?
Ә: Рәсемле футболкалар да, рәсемсезләре дә бар.
А: Рәсемсез футболка ничә сум тора?
Ә: 200 сум.

**Задание 2**

Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего **А – Г** и утверждениями, данными в списке **1- 6**. Используйте каждое утверждение из списка 1-6 **только один раз.** В задании есть **одно лишнее утверждение.**
Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу. У Вас есть 30 секунд, чтобы ознакомиться с заданиями.

**Сөйләүче А**

Монда кешеләр иртәнге, көндезге яки кичке ашны ашыйлар. Бирелә төрле ризыклар әзерлиләр. Гадәттә, мин монда көндезге ашны ашыйм. Ашлар бик тәмле!

**Сөйләүче Ә**

Монда китаплар, журналлар, газеталар укыйлар. Китапларны өйдә укырга да алып була. Монда эшләүче апалар бик игътибарлы.

**Сөйләүче Б**

Монда бик күңелле. Төрле спектакльләр карарга мөмкин. Спектакльләр көндез дә, кич тә була. Без һәр шимбәдә монда киләбез.

**Сөйләүче В**

Анда төрле хайваннар яшиләр. Дөяләр, арысланнар, жирафлар, маймыллар… Балалар анда булырга яраталар. Аларга хайваннар бик ошый.

**Сөйләүче Г**

Анда чит шәһәрләрдән, илләрдән килгән кешеләр яши. Алар анда берничә көн яшиләр. Монда бүлмәләр бик матур, уңайлы һәм чиста.

**Задания 3 – 8**

Вы услышите разговор двух друзей. В заданиях 3 – 8 обведите цифру **1, 2 или 3,** соответствующую выбранному Вами варианту ответа. Вы услышите запись дважды. У Вас есть 60 секунд, чтобы ознакомиться с заданиями.

Самат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Исәнме, Самат! Тагын укый башладык.
Самат: Әйе. Син җәен кайда булдың?
Алсу: Спорт лагеренда.
Самат: Лагерь кайда урнашкан?

Алсу: Урманда.
Самат: Син анда нишләдең?
Алсу: Саф һавада ял иттем, теннис, волейбол уйнадым, велосипедта йөрдем.
Самат: Су коендыңмы?
Алсу: Әйе.
Самат: Кайда?
Алсу: Күлдә. Урман янында бик чиста күл бар.
Самат: Лагерьда кызык булдымы?
Алсу: Әйе, бик кызык булды. Ә син кайда ял иттең?
Самат: Бакчада.
Алсу: Кояшта кызындыңмы?
Самат: Әйе, тагын футбол уйнадым, су коендым.
Алсу: Рәхәт булдымы?
Самат: Әлбәттә!

**ҖАВАПЛАР**

*1 нче таблица*

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 Диалоглар | 4321 | 17 | 5817246 |
| 2 | 34251 | 18 | ФАСЫЛЫ |
| 3 | **2** | 19 | ТИМЕРАЯКТА |
| 4 | **3** | 20 | УЙНЫЙЛАР |
| 5 | **3** | 21 | КЫШТАН |
| 6 | **2** | 22 | УРМАНДА |
| 7 | **1** | 23 | ЯЗДАН |
| 8 | **3** | 24 | ВАКЫТЫ |
| 9 | 2 | 25 | КӨННӘР |
| 10 | 1 | 26 | ТӨРЛЕ |
| 11 | 1 | 27 | БАЙЛЫК |
| 12 | 2 | 28 | ТАТАРЧА |
| 13 | 2 | 29 | ИСТӘЛЕКЛЕ |
| 14 | 1 | 30 | АҢЛАРГА |
| 15 | 1 | 31 | ӘҺӘМИЯТЛЕ |
| 16 | 2 | 32 | ФАЙДАЛЫ |

## Сөйләм ситуациясенә караган репликаларны бәяләү критерийлары

*2 нче таблица*

| № | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| *I* | *Язылган текстның эчтәлеге* | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |
| | Укучы, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган, төп сүзләрне дөрес кулланган.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Укучы сөйләм ситуациясенә караган репликаны **дөрес яки тулы** формалаштырмаган.<br>***Яки***<br>Төп сүзләрне кулланмаган.<br>***Яки***<br>Фактик хаталар бар.<br>***Яки***<br>Укучы **башка сөйләм ситуациясенә караган** реплика язган. | 0 |
| *II* | *Грамоталылык* | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә, тел нормаларының үтәлешенә караган хаталар юк<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 1-2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| Һәр реплика өчен максималь балл | | 2 |

**Укучы биремдә сорала торган сөйләм гыйбарәсе урынына башка гыйбарә яза икән, бу бирем тикшерелми.**

## Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары

*3 нче таблица*

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К 1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма | ***Эш өлешчә башкарыл-ган:*** 2 сорауга гомуми | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | тулмый |
| К 2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К 3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| К 4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **20** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Тест эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-18 балл – «2» ле билгесе;

19-38 балл – «3» ле билгесе;

39-53 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: әгәр укучы тыңлап аңлау буенча 5 баллдан кимрәк балл җыйса, «3» ле билгесе куела.

54-65 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: әгәр укучы тыңлап аңлау буенча 8 баллдан кимрәк балл җыйса, «4» ле билгесе куела.